КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 10 ноябрь г.Казань № 1061

2021 – 2023 елларда коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга «социаль һәм мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү максатларында мигрантларга консультация бирү һәм рус телен өйрәтү» иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү кысаларында кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт илкүләм сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2021 – 2023 елларда коммерциягә карамаган социаль юнәлештәге оешмаларга «социаль һәм мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү максатларында мигрантларга консультация бирү һәм рус телен өйрәтү» иҗтимагый файдалы хезмәт күрсәтү кысаларында кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен субсидияләр рәвешендә грантлар бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 4.2 пунктыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

бу карар кабул ителгән көннән ике атна эчендә коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларның субсидияләр рәвешендә грантлар бирүгә заявкаларын карап тикшерү комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга;

Тәртипне куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин